**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422725, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422725, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

тел./факс 8(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**29 ноябрь, 2022ел** **№ 66**

# Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 18.11.2019ел, № 194 «Җир салымы турында» Карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 булеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Закон нигезендә, «Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 18.11.2019 № 194 «Җир салымы турында» Карарына (Советның 19.05.2020 № 217, 16.11.2022ел №64 Карарлары редакциясендә) 7 пунктның 7.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәү юлы белән үзгәрешләр кертергә:

« - Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче Россия Федерациясе гражданнары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Бу карар 2021 салым чорына җир салымын исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина